МИНИСТР ӘЙТТЕ
Илсур Һадиуллин әти-әниләр, укытучылар, тәрбиячеләрнең сорауларына җавап бирде

> 2

БЕЛӘ ТОРЫП АЛДАНУ
Акчасын югалтучыларга ярдәм вәгъдә итәләр

> 2



ЧЕЧНЯ КӨНДӘЛЕГЕ
Журналист Гөлнара Җәлилованың Грозныйда күргәннәре

> 3

РӘХМӘТ, ТАБИБ!
Гыйрак егете Аммарның күп вакыты «кызыл зона»да уза

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 179 (28761) | Чәршәмбе | 8 декабрь | 2021 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

БУШЛАЙ «ЗӘҢГӘР ЯГУЛЫК»: КЕМГӘ ҺӘМ НИЧЕК?

Россия Президенты Владимир Путинның Федераль җыенга еллык Юлламасыннан соң илдә йортларны газга бушлай тоташтырып бетерү (догазификация) программасы эшли башлады. Моннан кемнәр һәм ничек файдалана ала? Эшне нәрсәдән башларга һәм программа ничәнче елга кадәр дәвам итәчәк? Халыкны кызыксындырган сорауларга «Газпром трансгаз Казан» оешмасы генераль директоры Рөстәм Усманов җавап бирде.

kazan-tr.gazprom.ru

Җитәкче сүзләренә караганда, программа 2023 елга кадәр дәвам итәчәк. Шушы вакыт эчендә республикадагы 903 торак пункттагы 18 меңнән артык йортның хуҗасы әлеге программага өметләнә ала. Дөрес, бу саннар үзгәрергә дә мөмкин.

– Газны кертеп бетерү – бизнес-проект түгел, ә безнең социаль бурычыбыз, – диде Рөстәм Усманов. – Әгәр 18 мең кеше гариза тапшыра икән, барысына да «зәңгәр ягулык» җибәрәбез. Гаризалар саны артып китсә, күбрәк тә эшли алабыз.

Программа ахырына кадәр 1200 чакрым газүткәргеч төзелергә тиеш. Нәтиҗәдә Татарстанда газлаштыру күрсәткечен 99,8 процентка җиткерү планы бар.

– Бу – Россиядә иң зур күрсәткечләрнең берсе, – диде җитәкче.

Аның сүзләренчә, әлегә 6,5 мең кешедән гариза кабул ителгән. Ел ахырына кадәр 687 йортка газ үткәрү планлаштырыла. Иң күп гаризалар Тукай районыннан кабул ителгән. Шулай ук Казанга якын булган районнарда да бу мәсьәләдә халык активлык күрсәтә. 2023 елга кадәр 4 млрд сум акча бүлеп бирелгән. Бу сумманың 2,3 млрд сумын – газлаштыру операторы – «Газпром газификация» оешмасы, ә 1,7 млрд сумын республика күтәрәчәк. Ләкин шунысы бар: программа халыкның мөрәҗәгать итүенә карап эшләнелә, ягъни халык никадәр актив булса, газлаштыру да шулкадәр кызу темплар белән барачак.

– Мин әлеге программа 2023 елда гына бетмәс дип фаразлыйм. Җитәкчелек аны озайтыр дип уйлыйм. Беренче еллар эшнең масштабын чамалар өчен кирәк иде, – диде Рөстәм Усманов.

Аңларга кирәк: әлеге федераль программа белән бергә республиканың газлаштыру программасы да эшли. Газлаштыру үз эченә бик күп эш-мәшәкатьләрне алса, газны тоташтырып бетерү (догазификация) дигәндә газүткәргечне газ бүлеп бирү үзәгеннән капка төбенә кадәр китереп җиткерү каралган. Һәм нәкъ менә шушы эш бушлай башкарыла. Тик шуны аңларга кирәк: газны участок буенча өйгә кадәр бушлай кертеп бирәләр дигән сүз түгел бу. Анысын хуҗаның үзенә подрядчы оешма яллап кертәсе. Проектын эшләтү дә, җиһазларын сатып алу да йорт хуҗасының үз җилкәсенә төшәчәк. Рөстәм Усманов әйтүенчә, бу эшләр өчен йорт хуҗасы ким дигәндә 80 мең сум түләргә тиеш булачак.

– Бәлки киләчәктә капканың эчке ягындагы эшләрне эшләү дә аерым бер категориядәге кешеләргә бушлай булыр. Бу турыда актив сөйләшүләр алып барыла. Без республика хөкүмәте белән фикерләшәбез. Монда иң мөһиме чыгымнарны кем каплавын аңлау кирәк, – диде Рөстәм Усманов.

«Газпром трансгаз Казан» җитәкчесе аңлатуынча, газны капка төбенә китереп җиткерү өчен берничә шарт үтәлергә тиеш. Беренчедән, бу ярдәм газ кертелгән торак пунктлар өчен генә актуаль. Ягъни газы гомумән булмаган авыл халкы моңа өметләнә алмый. Икенчедән, газ керәчәк йорт һәм җир рәсмиләштерелгән булырга тиеш. Өченчедән, газны йорт кирәк-ярагы өчен генә тоту. Ягъни аны йорт эчен җылыту һәм ризык әзерләр өчен генә куллану рөхсәт ителә. Бу программада бизнес-проектлар өчен газны бушлай кертеп бетерү каралмаган.

Моннан тыш, Рөстәм Усманов бушлай газ кертеп бетерү вакытын да әйтте. Газ бүлеп бирү үзәгенең никадәр якын һәм ерак арада урнашкан булуына карап, эшләү вакыты 3 айдан 12 айга кадәр сузылырга мөмкин.

Йортка газ кертү турындагы гаризаны җирле газ оешмасына килеп тапшырырга була. Шулай ук электрон юл аша да мөмкин. Монда халык «Дәүләт хезмәтләре» порталы һәм Газлаштыруның бердәм операторы сайтына кереп, мәгълүматларны тутыра ала.

Министрлар Кабинетында узган очрашуда журналистлар Сокуры, Каймар бистәләрендәге күпбалалы гаиләләргә бирелә торган йортларга газ кертү белән дә кызыксынды.

– Иң мөһиме – алар республиканың газлаштыру программасына вакытында эләгеп калырга тиеш. Ягъни монда район башлыкларына актив эшләргә һәм гаризаларны алдан тапшырырга кирәк. Бөтен документларга кул куелган очракта, газ кертеләчәк. Тагын бер кат кабатлап әйтәм: федераль программа белән бергә республика программасы бергә алып барылачак. Бу җәһәттән Татарстан темпларны киметмәячәк, – диде Рөстәм Усманов.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Шуннан да ким була алмый

Россия Президенты Владимир Путин 2022 елда минималь хезмәт хакы күләмен (МРОТ) аена 13890 сумга җиткерү турында законны имзалаган. Быелга исә аның күләме 12792 сум тәшкил итә.

Яшәү минимумы күләме дә үсә. Хәтерләсәгез, Владимир Путин ноябрь аенда социаль мәсьәләләр буенча киңәшмәдә ясаган чыгышында, киләсе елга федераль бюджет проектына яшәү минимумы күләмен 2,5 процентка арттыруның күздә тотылуын, әмма моның гына җитмәячәген билгеләп үткән иде. Шуңа күрә дәүләт башлыгы 2022 елга яшәү минимумы күләмен инфляциягә караганда күбрәк – 8,6 процентка арттыруны тәкъдим иткән. Шулай итеп, киләсе елда яшәү минимумы күләме аена 12 мең 654 сум тәшкил итәргә тиеш. Агымдагы елдагыга караганда бер мең сумга күбрәк бу.

Торак кредитын алучылар арта

1 ноябрьгә алынган мәгълүматларга караганда, Татарстанда бирелгән ипотеканың гомуми күләме, ел башыннан бирле 24,8 процентка артып, 338,2 миллиард сум тәшкил итә. Республикада яшәүчеләр гыйнвар – октябрь айларында барлыгы 54,8 мең торак кредиты (узган елның шушы ук чорындагыга караганда 11,1 процентка артыграк) алган. «Шушы чорда бирелгән ипотека күләме 137,9 миллиард сумнан артып китте инде (үсеш – 30,3%). Былтыр ел дәвамында бирелгән кредит күләменнән зуррак сан бу», – ди Россия Үзәк банкының Татарстан буенча бүлеге идарәчесе Марат Шәрифуллин. Аның әйтүенчә, Татарстанда яшәүчеләр кредитны вакытында түли. 1 ноябрьгә ипотека буенча җыелган бурыч кредитның гомуми күләменең 0,4 проценты чамасын гына (Россия буенча – якынча 0,6%) тәшкил итә.

Акча «бөке»дән коткара

kzn.ru

Россия Хөкүмәте төбәкләргә юллар төзү һәм төзекләндерү өчен 3 миллиард сумнан артыграк акча биргән. Шул ук вакытта аның яртысыннан артыграгы – 1,8 миллиард сумы Татарстанга юлланган. Бу хакта Министрлар Кабинетының матбугат хезмәте хәбәр итә.

Республикада әлеге акча Вознесение трактын төзүгә тотылачак. Ул башкаладан чыгу юлын М7 трассасы белән тоташтырып, Мамадыш трактында транспорт хәрәкәтен киметү мөмкинлеге бирәчәк. Шулай итеп, яңа юл Азино, Горки, Салмачы, Вознесенское, Привольный микрорайоннарында яшәүчеләрне «бөке»ләрдә утырудан коткарачак. Вознесение трактын төзү быел август аенда башланып китте.

Һава торышы

Декабрь буранга бай булачак

Атна азагына кадәр кар явачак. Аннары кабат суытачак. Синоптиклар бу көннәргә әнә шундый һава торышы вәгъдә итә. Белгечләрнең фаразларына ышансаң, декабрь бураннарга да бай булачак.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Билгеле булганча, бу көннәрдә Мәскәү карга күмелде. Белгечләр ил башкаласында соңгы җитмеш ел эчендә иң көчле явым-төшем буласын фаразлаган иде. Татарстанга бу циклонның «койрыгы» гына эләгер дип фаразлый синоптиклар. Анысы да, нигездә, Казанга туры киләчәк. Казан федераль университетының метеорология, климатология һәм атмосфера экологиясе кафедрасы мөдире, профессор Юрий Переведенцев сүзләренә караганда, ай дәвамында циклоннар еш күзәтеләчәк. Декабрьдә бураннарның күп булачагы да әнә шуның белән аңлатыла. «Балкан ярымутравыннан килгән циклон безгә дә кагылып китәчәк. Атна азагына кадәр кар явачак, 10 мм явым-төшем көтелә. Аннары кабат суытачак», – диде ул журналистлар белән очрашуда.

Белгечләр узып баручы елның һава торышын «холыксыз» дип бәяли. Хәтерләсәгез, ел башы зәмһәрир суыклар белән башланып китте. Ул хәтта метеокүзәтүләр тарихындагы иң салкын ун кыш арасына кертелгән. Быел җәй дә, гадәттәгедән аермалы буларак, дүрт айга сузылган. «Быелгы җәй гадәттәгедән 21 көнгә озаграк булды. Җылылык җитәрлек булса да, явым-төшемгә кытлык булды. Уңыш өчен иң кирәк чакта яңгыр булмады. Аның каравы быелгы ноябрь бу яктан рекорд куйды. Шушы бер ай эчендә республикада 95 мм явым-төшем теркәлде. Соңгы тапкыр ноябрь аенда мондый рекорд 2002 елда куелды. Ул чакта явым-төшем күрсәткече 107 мм булган иде», – дип сөйләде КФУның метеорология, климатология һәм атмосфера экологиясе кафедрасы доценты Тимур Әүхәдиев.

Синоптиклар, быелгы декабрь гадәттәгедән күпкә җылырак булачак, дип ышандыра. Уртача тәүлеклек температура 9 градуска югарырак булыр дип көтелә. Декабрьнең икенче яртысында көннәр суытачак. Шулай да быел кышын көчле салкыннар көтелми, дип фаразлый белгечләр. Сүз уңаеннан, синоптиклар һаваның елдан-ел җылына баруын искәртә. Юрий Переведенцев сүзләренә караганда, соңгы 120 ел эчендә һаваның уртача температурасы 1,1 градуска күтәрелгән. «Бу – бик зур күрсәткеч», – ди белгеч.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Сүзгә-сүз

Михаил МУРАШКО, Россия сәламәтлек саклау министры:

Менә инде икенче атна медицина күзәтүе астында булган коронавирус белән авыручылар саны кимүен теркибез. Кимү күрсәткече атна эчендә 11 процентка җитте. Авыру очраклары кимү планлы медицина ярдәмен күрсәтергә һәм хастаханәгә эләккән пациентларга күбрәк игътибар итәргә мөмкинлек бирә. Ясалма вентиляцияләү аппаратына тоташтырылган сырхаулар саны элеккечә югары кала. Бу – 5156 кеше.

(Коронавирус инфекциясенә каршы көрәш буенча координацион совет утырышындагы чыгышыннан)

РОССИЯДӘ – БӘЯЛӘР АРТУ

Россиядә яшәүчеләрнең барыннан да бигрәк азык-төлеккә, бензинга һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләренә бәя арту ачуын китерә икән. Бу хакта SuperJob хезмәтенең сораштыру нәтиҗәләре сөйли.

НӘРСӘГӘ БӘЯ АРТУ КҮБРӘК БОРЧЫЙ?

Азык-төлек	50%
Ягулык	17%
Торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре	11%
Транспорт	5%
Дару, медицина хезмәтләре	4%
Торак, төзелеш материаллары, кием-салым	2%

Чүплек газы файда китерәчәк

Казанның «Самосырово» чүплеге янында чүплек газыннан электр энергиясе җитештерергә мөмкинлек бирәчәк электр станциясе төзеләчәк. Россиядә тәүге шундый корылма булачак бу.

Хәзер полигонны тәртипкә салу-зарарсызландыру эшләре башланган. Рекультивация эшләре төгәлләнгәннән соң 1 миллион тоннадан артыграк калдык тупланган полигон агач-куакларга күмелгән яшел калкулыкка әйләнеп калачак. Эшләр барышында калдыклардан чыккан газларны җыю системасын урнаштыру күздә тотыла. Моның өчен 80 газ торбасын чүплеккә 18 метр тирәнлеккә батырып, газүткәргеч сузу планлаштырыла. Шул рәвешле җыелган чүплек газын электр станциясе өчен ягулык сыйфатында файдаланырга ниятлиләр. Аның күләме 15 елга җитәргә тиеш. Проектны гамәлгә ашыруга «Чиста ил» федераль программасы кысасында 876,5 миллион сум акча бүлеп бирелгән.

Казан мэры Илсур Метшин әйтүенчә, рекультивация эшләре 2023 елның ноябрь – декабрь айларында тәмамланырга тиеш.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

БОМБАЛАР ҺӘМ САНКЦИЯЛӘР БЕЛӘН КУРКЫТУ

Дөнья сәясәтендә вакыйгалар АКШ – Россия, Көнбатыш – Россия күчәре тирәсендә төйнәлә бүген. Байден – Путин видеоэлемтәсе алдыннан Вашингтон Россиягә каршы хәрби һәм икътисади басым ясауның барлык юлларын да кулланырга омтыла.

Конфликтның төйнәлүен океан артындагылар Россия гаскәрләренең Украина чикләре буенда тупланы һәм яңа агрессиягә омтылы белән аңлата. Мәскәү исә коралы көчләрен көнбатыш чикләргә күчерүне НАТОның Украинадагы активлыгы белән бәйли. Элекке совет республикасы Көнбатыш атлантик блокка керсә, дошман ракеталарының Россия башкаласына 5 минут эчендә килеп җитә алачагын төп куркыныч итеп санавын яшерми. Бик куркыныч вазгыять бу, чынлап та.

Соңгы көннәрдә генә Америка галимнәре федерациясе Вашингтонның 2025 елга кадәр В61-12 модификациясендәге өр-яңа 480 атом-төш тактик авиабомбасын җитештереп, Европада урнаштырырга җыенуын белдерде. Бу Кытай, Франция, Британия, Пакъстан, Һиндстан, Төньяк Корея һәм Израильнең атом-төш арсеналыннан күбрәк. Яңа бомбалар стратегик стелс-бомбага тотучы В-2 Spirit һәм яңа эшләнүче В-21 Raider хәрби очкычларына яраклаштырылып эшләнә. Европада бүген янкиларның 100–150 тактик атом-төш бомбасы барлыгын исәпкә алганда, тагын 480 куплап юк итү коралын урнаштыру россиянеләрне борчуга салмый калмый, билгеле. Сер түгел: Европа театрындагы барлык коралар да бары тик Россиягә каршы гына юнәлтелә. Атлантик блокның ул төбәктә башка дошманы юк. Бөтен өмет, әлбәттә, коралларның бары тик куркыту өчен генә туплануында. Атом-төш дуэле беркемне дә кызыксындырмый дип уйлыйк инде.

Океан артыннан тагын бер хәбәр бар: имештер, Вашингтон, Россия Украинага һөҗүм итсә дә, аңа хәрби җавап бирергә җыенмый. Бары тик икътисади басымны чамасыз көчәйтергә генә ниятли. Россия банкларын халыкара түләүләр системасы SWIFTтан өзү, Путин даирәсендәгеләргә персональ санкцияләр кертү, Россия әҗәт кәгазьләрен сатып алудан тулысынча тыю кебек бары тик Иранга һәм Төньяк Кореяга каршы гына кулланылган чараларны тормышка ашыру бары белән янылар. Бу чараларның кайберләре өлешчә генә тормышка ашырылып килә инде. Яналар пакеты тулысынча тормышка ашырылса, безнең матди як, чынлап та, бик нык авыраячак. Чит илләргә акча күчерү мөмкин булмаячак, сәүдә иткәндә, долларны капчыклап ташырга туры киләчәк. Безнең товарларны сату, читтән товар кайтару бик нык кыенлашачак. Россиянең төп товары – чимал гына инде, билгеле. Көнбатыш үзе дә ул чималга бәйле. Шуңа күрә бу тыюлар гадәттән тыш шартларда гына тормышка ашырыла ала. Россия олигархлары һәм чиновниклары өчен персонал санкцияләр куркыныч. Бу – читкә чыгарып яшерелгән акчаң бикләнү дигән сүз. Сәддам Хөсәен, Каддафи активлары белән ни булганын хәтерлибез бит әле. Байден – Путин элемтәсеннән соң вазгыять ачыклана төшәр, мөгаен. Мәскәүдә дә, Вашингтонда да хәлләрнең алай ук кискенләшүен теләмиләр дип беләбез.

Россиядә

ЧҮП ҮСТЕРМӘ, ТӨЗЕ

Көнбатыштан янаулар фонында Россиянең финанс базарында җинелчә артка китү сизелә. Фонд базарында төшенкелек хөкем сөрә, сум очсызлана... Мондый шартларда гади халыкка да тормыш алып бару җиңел түгел. Соңгы хәбәрләр кешеләрнең торакны бары тик кредитка гына алуларын, үз акчасы юклыгын сөйли.

Путин исә яңа гына кредит бирүне чикләү турында законга имза салды. Бәндәләренең әҗәткә булган нәфесләрен чикләү начар гамәл түгел ул үзе, процентлы кредитларны бөтенләй тыйсаң да, зыян итмәс иде. Әмма әлегә кертелгән чикләүләр дә артык кырыс түгел, ипотека һәм автокредитка алар, мәсәлән, бөтенләй кагылмый. Кредитласаң, кредитламасаң да, автомобиль базары түнтәрелештә, төзелеш тә озакламый түбәнгә тәгәрәргә мөмкин. Менә бу үткән җәйдә Казан тирәсендә төзелеш бик нык кайнады кайнавын. Төзелеш материалларына бәя үскән саен, аларга ихтыяҗ да артты гына тәсле. Яңа йортлар гөмбә кебек үсеп чыктылар. Бистә читендә җир алучыларның йорты бик тиз эчтә калды.

Төзелеш күбрәк компанияләр хисабына үсте. Үз көчләре белән шәхси йорт төзүчеләр артыгын кылана алмый. Кемдер нигез салып куя белән чикләнә, мөмкинлеге булганнар түбә астына кертеп калырга тырыша, сатып алынып та, тик яткан җирләр дә байтак. Менә бу соңгыларына карата штраф белән йогынты ясарга телиләр. Җир алгач, төзелеш башлауның үз тәртибе бар бит аның. Билгеле бер срок эчендә төзелеш башланырга тиеш, билгеле бер вакыттан соң аны төгәлләү дә таләп ителә. Шундый законы бар аның Россиядә. Әмма дә ләкин шәһәр тирәсендәге участокларның шактый ук кыйммәт йөрүен исәпкә алсак, бөтен егәрне җир алуга тотып бетергәч, тиз генә төзелешкә старт бирү бик кыен. Кайберәүләрнең йорт урынын чүп үлән басып, еллар буе ятә. Аңлашыла инде: россиялеләрнең өчтән бере хезмәт хакын ай ахырына кадәр җиткерә алмауларын таныйлар. Ничек төзелеш алып барасың инде андый шартларда? Йорт урыны алучылар арасында да кыен хәлдә калучылар бихисап.

Әлегә кадәр аларга карата җитди санкцияләр кулланылмады диярлек. Соңгы вакытларда судлар бу мәсьәләдә активлык күрсәтә башлады. Чиновниклар тик яткан җирләр турында актлар төзеп, казыйларга тапшыра да, җәза машинасы хәрәкәткә килә. Төзелеш өч ел эчендә башланмаса, шундый акт язылырга ихтимал. Бу очракта КоАП (административ тәртип бозулар кодексы) 20 мең сумнан 50 мең сумга кадәр штраф белән яный. Штраф җирнең кадастр бәясенең 1–1,5 проценты кадәр итеп исәпләнә, әмма 20 меңнән да ким була алмый. Гражданлык кодексында файдаланылмаган җирне (төзелеш башланмаган) тартып алу ихтималы да каралган. Дөрес, җир хуҗасы төзелеш башлый алмавының объектив сәбәпләрен әйтеп, бәхәскә дә керә ала. Тик менә кесә буш дип зарлануны казыйлар игътибарга алмаска мөмкин. Дәлилле һәм җитдирәк сәбәпләр табарга туры килә. Төзи алмыйсың икән, участокны койма белән әйләндереп алып, чүбен утап торырга кушалар. Дөрес, аның коймасы да ярыйсы бәягә төшә хәзер. Тик акча юклыкка сылтасаң, бик язмыш дигәндә штраф күләмен 10 мең сумга кадәр киметергә ихтималлар. Шуңа күрә җир алганчы, мөмкинлекләреңне яхшылап исәпләргә туры килә.

ВАТАН ГЕРОЙЛАРЫ КӨНЕ БЕЛӘН!

Татарстан Президенты Рөстәм МИҢНЕХАНОВның Ватан Геройлары көне уңаеннан МӨРӘҖӘГАТЕ

Хөрмәтле татарстанлылар!

Сезне Ватан Геройлары көне уңаеннан чын йөрәктән котлыйм.

Безнең илдә бу бәйрәм 2007 елдан билгеләп үтелә. Ул төрле чорларда халкыбыз һәм дәүләтебез мәнфәгатьләрендә ихлас тырышлык куйган, сугышчан һәм хезмәт батырлыклары кылган фидакарьләрне – Ватанның данлыклы уллары һәм кызларын хөрмәтләү йөзеннән билгеләп үтелә.

Бу бәйрәмнең барлыкка килүе Россиядә 1769 елның 9 декабрендә гамәлгә куелган Изге Георгий ордены кавалерлары олылау, тәбрикләү традициясе белән бәйләнгән. Ватан каһарманнарын шул рәвешчә зурлау Россия халыкларының хәрби-патриотик һәм мәдәни мирасын буыннан-буынга тапшыру, рухи хәзинәләренең кыйммәтен, илебезнең тарихы белән ихлас кызыксынуны арттыру һәм шанлы үткәнебез турындагы хәтер-хатирәләрне мәңгеләштерү өчен гаять мөһим.

Советлар Союзы Геройлары, Россия Федерациясе Геройлары, Социалистик Хезмәт Геройлары һәм Россия Федерациясе Хезмәт Геройлары, Изге Георгий ордены кавалерлары безнең өчен батырлык һәм кыюлык, үз-үзеңне аямыйча туган илгә хезмәт итү үрнәге булып тора. Алар арасында Муса Җәлил һәм Газинур Гафиятуллинның, Петр Гаврилов һәм Михаил Девятаевның, Мәгубә Сыртланова һәм Гази Заһитовның, Борис Кузнецов һәм Әхтәм Сабировның, Илдус Мостюков һәм Николай Фроловның, Минтимер Шәймиев һәм Газинур Хәйруллинның, шулай ук башка бик күп мәшһүр ватандашларыбызның исемен зур горурлык белән атыйбыз. Бу олуг шәхесләрнең тормышы, игелекле эшләре балаларда һәм яшьләрдә, Татарстанда яшәүче һәркемдә гражданлык һәм ватанпәрвәрлек хисе тәрбияләү өчен бәрәкәтле җирлек булып тора. Ватан Геройларын турында якты истәлекләрне кадерләп саклау, исәннәрен һәрчак игътибар үзәгендә тоту – безнең буынның әстенлекле тарихи максаты, варислар алдындагы олы бурычы.

Ватан Геройларына һәм барлык татарстанлыларга нык сәламәтлек, бәхет, тынычлык һәм иминлек телим!

Бергә көрәшү кирәк

9 декабрь – Коррупциягә каршы халыкара көрәш көне. Бу уңайдан Татарстан Премьер-министры Алексей ПЕСОШИН газетабыз аша республикада яшәүчеләргә мөрәҗәгать белән чыкты.

«Татарстан коррупциягә каршы технологияләр һәм институтларны гамәлгә кертү буенча алдынгы сафларда бара, – диелә мөрәҗәгатьтә. – Бүген республикада Министрлар Кабинеты карары белән расланган «2015–2024 елларга Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәтне тормышка ашыру» программасы гамәлдә. Программага 121 чара кертелгән. Аларны тормышка ашыруда федераль, республика һәм муниципаль хакимият органнары, шулай ук иҗтимагый оешмалар катнаша. Программаның төп максаты – коррупция сәбәпләрен ачыклау һәм юкка чыгару, аңа каршы нәтиҗәле көрәшү өчен шартлар, җәмгыятьтә әлеге күренешкә карата тискәре мөнәсәбәт булдыру.

Коррупциягә каршы эшчәнлек – даими үсештә. Аны кисәтүнең яңа ысуллары эзләү буенча зур эшләр башкарыла. Шул ук вакытта социологик тикшеренүләр юлы белән халыкның коррупция турында фикере дә исәпкә алына. Дәүләт программасы, җәмгыятьтә әлеге куркыныч күренешнең чагылышларын кимету һәм алга таба аны юкка чыгару өчен, куелган бурычларны хәл кылуда бик үтемле ысул булып тора».

АЛДАНГАННЫ ТАШЛАМЫЙЛАР

МОШЕННИКЛАРДАН ЗЫЯН КҮРҮЧЕЛӘРГӘ ЯРДӘМ ВӘГЪДӘ ИТӘЛӘР

Курыкканда аң томалана икән ул! Бер ай элек кырыгалдарларга 284 мең сум акчасын чыгарып салган Әлмәт егете Рәсим шулай ди. Ят номердан шалтыраткан, үзен банк хезмәткәре дип таныштырган ир-ат белән сүзне кыска тотып, трубканы куярга гына җыенган ул башта. Тик тегесе егетнең исем-фамилиясен, карта номерларын, соңгы тапкыр ничә сум акча күчергәнлеген әйтеп биргәч, туктап кала.

pixabay.com

«Алдагы көнне генә иптәш егеткә 2 мең сум акча күчергән идем. Шунысына кадәр үк дөрес әйтеп биргәч, минем исемгә кемнеңдер кредит рәсмиләштерергәнә дә ышандым инде. Операцияне тизрәк туктату өчен яңа кредит рәсмиләштерергә кушты ул. Имеш, документлар әле каралмаган, һавада эленеп тора икән. Кредит рәсмиләштергәч, акчаны ул кушкан счетка күчердем. Шуның белән сөйләшү дә өзелде. Кире шалтыратам – трубканы алмыйлар, соңрак телефонны бөтенләй сүндереп үк куйдылар. Алданганымны шунда гына аңладым», – ди Рәсим. Банкта аңа, бу сумманың 30 мең сум чамасын гына киреп кайтарып булачак, дигәннәр.

Әлегә банклар алданганнарга сугаа салган акчаның күп дигәндә 8 процентын гына кире кайтара ала. Якын киләчәктә аның күләме артырга мөмкин. Россия Үзәк банкы законга тәзәтмәләр тәкъдим иткән. Алар кабул ителсә, алданган кешегә кире кайтарыласы акчаның минималь күләме билгеләнәчәк. Дөрес, моның шартлары да булачак. Әйтик, алдану очрагы турында тиз арада банкка хәбәр җиткерергә кирәк.

Аңлашыла инде, банкларга да таләпләр артачак. Законга яңа үзгәрешләр кертә калса, алар шикле тоелган исәп-хисап операцияләрен шундук туктатырга тиеш була. Моннан тыш алар клиент ризалыгыннан башка гына аның счетыннан акча күчерергә маташуны күрсәткән операцияләрне биш көнгә туктатып тора алачак. Шул рәвешле Үзәк банк кырыгалдарлар тарафыннан алданучылар санын бермә-бер киметергә җыена.

Белгечләрнең бер өлеше исә бу фаразларның тормышка ашачагына шикләнеп карый. «Банклар югалткан акчаның шактый өлешен кире кайтара башлаган очракта да банк белән бәйле алдау очраклары кимемәячәк. Гадәттә, кырыгалдарлар яшен тизлеге белән эш итә. Кеше үзенең алданганын аңышырга өлгергәндә инде еш кына тиешле операция дә башкарылган, счеттагы акчадан да җилләр искән була. Монда көннәр түгел, минут, секундлар турында сүз бара», – ди юрист Илнур Гарифуллин.

Рәсми саннардан аңлашылганча, быелның өченче кварталында гына да ил халкы кырыгалдарларга 3,2 миллиард сум акча күчергән. Банклар исә бу сумманың нибары 7,7 процентын, төгәлрәк әйтсәк, 250 миллион сумын гына кире кайтарган.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Ял дигәндә, «омикрон» куркытмый

Яңа ел якынлашкан саен, ял кәефе дә барлыкка килә. Халыкны чир белән генә куркытып булмый. Саннар да шуны дәлилләп бит: чит илләргә чыгу ихтыяҗы да, тур бәяләре дә кискен арткан. Туристик индустрия вәкилләре әйтүенчә, Россиядә, ноябрь ае белән чагыштырганда, яңа ел турларының бәяләре 20–30 процентка арткан.

Билгеле булганча, Африкада коронавирусның яңа штаммы – «омикрон» дигәне табылды. Россиядә аның ике очрагы барлыгы расланды инде. Инфекцияне Көньяк Африка Республикасыннан кайткан 2 кешедә ачыкланганнар.

Россия туристик операторлары ассоциациясе белдергәнчә, коронавируска бәйле яңалыклар ял итәргә җыенучы туристларны әллә ни куркытмаган. Киресенчә, Мисырга очышлар күбрәк тә кызыксындыра башлаган.

Әлегрәк Роспотребнадзор идарәсе башлыгы Анна Попова да ил халкына Яңа елны өйдә генә каршыларга, чит илләргә чыгудан баш тартырга киңәш иткән иде.

– Россия гражданнарыннан Яңа елны өйдә уздыруларын сорыйм. Вазгыять үзгәрүчән. Ялга җыенучыларның күп кенә, шул исәптән сәламәтлеккә бәйле проблемалар белән очрашу ихтимал. Акчаны гына түгел, сәламәтлекне дә югалтырга мөмкин, – дигән иде ул бер утырышта.

Россия туристик индустрия берлеге вице-президенты Дмитрий Горин әйтүенчә, Яңа ел турларын сату кимемәгән. «Киресенчә, 2020 ел белән чагыштырганда, күбрәк туристлар киләсен көтәбез, 70ләп ил чикләре ачык, чартерлар очып тора», – дип белдергән ул.

Гомумән, ил халкы өчен Төркия һәм Мисыр гомер-гомергә ял итү өчен яраткан курортлар саналды. Коронавирусы чорда аларның туристларны QR-кодсыз гына кертүләре дә, күп кенә илләрнең ябык булуы да үз нәтиҗәсен бирми калмыйдыр.

ИЛСУР ҺАДИУЛЛИН:

«МӘКТӘПКӘ АУДАРЫП КАЛДЫРМАГЫЗ»

Киләсе елның гыйнварыннан укытучыларның хезмәт хакы артачак. Республикада дүртенче категориягә кертелгән мәктәпләрдә сак хезмәте мәсьәләсе хәл ителәчәк. Бу хакта Татарстан мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин хәбәр итте. Туган телне өйрәтү өчен, министр әти-әниләргә өйдә татарча сөйләшергә кушты.

Сәгать ярым дәвамында министр «туры элемтә» аша әти-әниләр, укытучылар, тәрбиячеләрнең сорауларына җавап бирде. Күпләрне биш көнлек укытуга күчү, укытучыларның хезмәт хакын күтәрү, бакча, мәктәпләр төзү, төзекләндерүгә бәйле проблемалар борчый булып чыкты.

Биш көнлек укыту турында

«Туры элемтә»дә һәр өченче кешенең берсен, биш көнлек укытуга күчмибезме, дигән сорау кызыксындырды. Әйтик, быел Түбән Камада 35 мәктәптә шимбә укытмый башладылар.

– Казан, Әлмәт, Түбән Кама шәһәрләре һәм авыл районнарында биш көнлек укытуга күчкән мәктәпләр бар. Бу мәсьәләне мәктәп әти-әни, укытучылар белән бергәләп хәл итә. Төрле сәбәпләр бар. Уку планы үтәлергә, рус теле, туган телләр, башка фәннәр дә тулы күләмдә өйрәнелергә тиеш. Дәресләр күп булса, балалар арый башлаячак. Без бит андый тикшеренүләр алып бардык. Монда этнокультура, төбәк үзенчәлекләрен дә исәпкә алу мөһим. Казанда – 83 мәктәп (25е – башлангыч мәктәпләрдә), Әлмәттә – 7, Алексеевскида – 23, Актанышта кадетлар мәктәбе укучылары атнага биш көн укый. Ашыгырга кирәкми. Балаларның сәламәтлеге турында уйлап эш итү мөһим. Таләпләрне үтәгәндә генә күчәргә була. Аннан үзегез үк, балаларны белемсез калдырасыз, диячәксез, – дип киңәш бирде Илсур Һадиуллин.

Мәктәпләрдә иминлек мәсьәләсе турында

Яңа уку елында беренче һәм икенче категориядәге мәктәпләрдә иминлек мәсьәләсен хәл итү өчен – республика, ә өченче төркемгә керүче белем оешмаларына район бюджетыннан акча бүлеп бирә башладылар. Киләсе елдан моның өчен 1 миллиард сумнан артык акча бүленәчәк.

– Барлык төбәкләр дә мондый карарлар кабул итмәде. Дүртенче категориягә кергән мәктәпләргә бәйле проблема да хәл ителәчәк. Бездә беренче категориядәге – 73, икенчедә – 207, өченче төркемгә кергән 1787 мәктәп исәпләнә. Республикада 2 меңнән артык мәктәп бар. Алар барысы да сак хезмәте белән тәэмин ителәчәк. Балалар өчен уңай мохит булырга тиеш, – диде министр.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Бакчалар, мәктәпләр төзү турында

Биектау районының Шигали авылындагы бакчага әлегә алмыйбыз, Озерный бистәсендәге мәктәптә балалар сан ике мәртәбә артып китә, дип мөрәҗәгать иттеләр министрга.

– Республикада бакчалар төзелә. Төрле программалар бар. Быел – 17 бакча, шуның 13е «Демография» илкүләм проекты буенча төзелә. 2390нан артык урын булдырылса, шуның артыгы – әсле төркемнәре өчен. Биектаудагы проблеманы да беләбез. Лаеш, Казаннан да шундый ук сораулар килде. Президент Рөстәм Миңнеханов тарафыннан бакчалар төзү, заманча җиһазлар белән тәэмин итү буенча күп нәрсә эшләнә. Ләкин кечкенәләр төркемнәре буенча кыенлыклар бар әле. Без бу сорауларга ачыклык кертеп, сезгә җавап бирербез. Якын-тирәдәге бакчалардан урыннар тәкъдим итәрбез, – дип җавап бирде министр.

Яңа уку елында Татарстанда 7 мәктәп ачылды. Берсе «Мәгариф» илкүләм проекты, башкалары исә республика хисабына төзелгән. Мәктәпләр төзү балалар саны буенча хәл ителә. «Казан, Әлмәт, Түбән Кама, Чаллы, Питрәч, Биектау районнарында җитәкчелек яңа мәктәпләр төзүгә аеруча игътибар бирә. 2023–2024 елларда Казанда Сибгат Хәким урамында 1224 урынга исәпләнгән мәктәп төзү планлаштырыла. Республика мәктәпләрне төзекләндерү буенча федераль программага 139 уку йортын тәкъдим итте. Әйтик, 2022 елда – 69, 2023 елда 30 мәктәп керергә тиеш. «Мәгарифне үстерү» федераль программасы бар. Анда 14 мәктәп тәкъдим ителде», – диде республиканың баш педагогы.

Укытучылар җитмәү турында

Укытучылар җитмәү проблемасын хәл итү өчен ни эшләнәчәк?

– Республикадагы укытучыларның 25 процентдан артыгы – яшьләр. Педагогларның уртача яше – 44–45 яшь. Бүген республикада физика, рус теле, математика, биология һәм химия укытучыларына кытлык бар. 7 һәм 8 сыйныф укучылары арасында һөнәргә өйрәтү эшен алып барырга кирәк, – диде Илсур Һадиуллин. – Укытучылар олыгая, арыйлар. Әмма бу республика укытучыларсыз калачак дигән сүз түгел. Без төрле чаралар күрергә тиеш. 2022 елның 1 гыйнварыннан мәгариф тармагында бюджет әлкәсендә эшләүчеләрнең хезмәт хакы артачак. Кече тәрбияче, пешекчеләр, техник персонал, укытучылар, методистлар, урынбасарлар, директорларга да кагыла бу. Уртача алганда, оклад 2,5–5,5 мең сумга кадәр артачак. Аннан соң кызыксындыру һәм компенсация түләүләре дә күтәреләчәк. Сыйныф җитәкчелегенә сыйныф өчен – 550 сум, һәр укучыга – 80 сум, шулай ук 5 мең сум федераль акча түләнә.

Татар теле турында

Әти-әниләрнең берсе 4 сыйныфта татар теленнән уздырыла торган диагностик эшләр турында: «Яңадан катлаулы кагыйдә ятлатуга әйләнеп кайту була бит бу», – дип ризасызлык белдерде.

– Борчыларга урын юк. Бу – балаларның туган телне ни дәрәҗәдә белүен тикшерү. Тел төбегездә нәрсә ятканын аңладым. Кагыйдә генә ятлатып, аралашырга өйрәтмичә, үзебезнең матур туган телебезгә мәхәббәт уятып булмый. Өйдә татарча сөйләшергә кирәк. Барысын да мәктәпкә аударып калдырмагыз. Башка телдә дә сөйләшегез, әмма үзегезнекен онытмагыз, – дип киңәш бирде Илсур Һадиуллин.

Сәрия МИФТАХОВА

vk.com

ҖИРСҮ

Чечня көндәлеге

Чечен Республикасында яши башлаганга – 2 ел. Аз да түгел, күп тә түгел. Шул башыма китереп сукты да, үзем дә таң калып утырам – әле кичә генә кебек.

Күченү

Иремнең эше буенча Казаннан кубарылып, әлеге республикага күченәсен белгәч, бу яңалыкны иң тыныч кабул иткән кеше минем әти булгандыр.

– Иии, кызым, – диде ул, суза төшеп. – Өч елмы, бишме, җидеме – сезнең тормыштагы кечкенә бер нокта гына булачак, рәхәтләнеп яшәп кайтыгыз, олыгайгач, искә алыр истәлегегез булыр…

Акыллы сүз өлкәннәр теленнән яңгырый ич инде ул. Безнең кабул итү зирәклеге генә көне-сәгатендә сукмый, вакыт белән килә.

Килеп урнашкан көннәрне искә алам: башта аның берние дә булмады. Нәкъ ялга барган шикелле инде – яңа тирәлек, матур, төзек республика. Грозныйның кыл уртасына килеп урнаштык, бөтен нәрсә – кул астында гына. Кыскасы, ял. Олы кызыбыз Мәрьямгә – мәктәп, кечкенәбез Әминәгә балалар бакчасы хәстәрләп, атна-ун көнләп узды. Аның белән беррәттән фатирыбызга хатын-кыз кулы кертәсе бар, тегесен алам, бусын урнаштырам. Мәш килеш, кыскасы. Шул мәшәкатьләр белән күкрәк турысындагы «командир»ны ишетмәмешкә дә салышам. Ә ул, кирлемән, башта чын зыялыларча башлаган иде: ярар, килдек, күрдек, эһе, матур, хәзер өй тарафларына кайту хәстәрен күрергәдер. Кайту якын-тирәдә генә юк икәнне аңлауга, шыңшуга ук күчә башлады, бер төнне мендәр шыр юеш булганчы үксеп тә чыкты. Бернәрсә дә күзгә күренми башлауны үзе читтә яшәп, җирсеп, туган туфрагына кайтып егылырга теләгәннәр генә аңлыйдыр. Минем моңарчы читтә яшәп караган бармыни – мин бит моңарчы иң бәхетле кешеләр ел әйләнәсе кояш сырт кыздырган диңгез ярында яшиләр дип белә идем! Ялган икән! Иң бәхетлеләр бот төбеннән кар ерып, зәмһәрир салкыннары, пыскак яңгырлы кара көзләре, черки-кигәвенле, печән өсле Татарстанда яшиләр икән. Грозныйда җылы, рәхәт бит, бездә салкын, урамнарны кардан чистартмыйлар, тик ят шунда тәмле җиләк-җимешләр ашап, дип язып та тордылар үзе. Ә мине инде бернәрсә белән алдап булмый – сагыну сулкылдауга, инрәүгә әйләнгән иде. Үз өемне, әти-әни, туган-дусларны сагыну гына да түгел иде ул – туган авылның зиратына кадәр юксыну барлыкка килде.

Ә килмешәклек – Грозныйда килгән-киткән кешегә алай ким итеп карау гомумән юк икән. Киресенчә, безнең – татар, кызларыбызның Мәрьям, Әминә булуын белүгә, ниндидер җылылык та өстәлде бугай әле. Өй янында җиләк-җимеш сатучы апалар, башларыннан сөеп, аркаларыннан кагып, әле бер, әле икенче күчтәнәч төяргә генә торды.

Монда килгәнче, бик күпләр шикелле мифлар тарафдары идем мин дә. Хәзер дә язалар әле миңа: «Бала-чага шикелле тегеңә дә, моңа да сокланып йөрмә инде, ул – бик үзенчәлекле республика». Үзенчәлексез республика була аламыни ул? Мин шәхсән андыйны белмим. Грозныйда чат саен юкка полиция мылтык тотып йөрми инде, янәсе. Мине дә ул башта шөлләткән иде. Әмма тора-бара аларның, чыннан да, куркынычсызлык сагында булуын аңлагач, мин аларның күбесе белән исәнләшеп тә үтәргә ияләндем. Карантин вакытында өйдән чыгарга катгый ярамый, ирем дә: «Чыга күрмә», – диде. Айдан артык дүрт стена эчендә утырганнан, сабырлык төкәнгәннән соң, Җәлилова түзмәде – юлның кыл уртасында мылтык тотып сакта торган полицейскийга таба юнәлде. «Баламны ун-унбиш минутка булса да һава сулатырга алып чыгасым килә», – дидем. «Алып чык, подъезд янында гына йөр, мин сине күрмәдем», – диде ул.

Әнә шул дәү мылтыклар тотып йөргән әзмәвердәй полиция егетләренең Әминәнең битеннән чеметкәләп, сумкадан кәнфит чыгарып бирүләрен күрергә кирәк. Йөрсеннәр генә, исән генә булсыннар. Монда – полициягә тулаем ышаныч һәм хөрмәт. 20 ел Казанда яшәп, гомергә бер участок полицейскиеның кем икәнен ишеткән-белгән юк иде, монда һәр өйдә участковыйның телефон номеры, фотосы тора.

Ә фатирлар… Фатирларның берсе бер бикләнми. Грозныйның теләсә кайсы урынына машинагызны куеп, бикләмичә, тәрәзәләрен җилләтергә ачык куеп калдыра аласыз – безнең күрше-тирәләр шулай итә. Без дә, кибеттәнме, базарданмы төянеп кайтсак, машинаның артын ачып куеп, сумкалар ташырга өйрәндек. Башта, һай, ышаныч юк иде – гадәт китми, дигәннәре шул икән…

Былтыргы А

Студент булып Казанга, шәһәргә килеп урнашуга алны-артны карап йөрү, акның ак булуына шикләнү гадәте сеңде. Кеше кешегә ышанмас, таянып булмаслык, күрше белән күрше, туган белән туган аралашмас вазгыятькә килеп терәлдек ич инде. Аның төбен казый башласаң, ни генә чыкмый, әмма иң юан шеш булып тәкәбберлек тора. Бер-берен уздырырга тырышып яшәү шундый тизлеккә җитте ки – кешеләр бер-берсен күралмау дәрәҗәсенә килеп терәлде, гадәти, гади әйберләрнең тәме киттеме шунда… Без беркемгә дә ышанмаска өйрәнеп беттек.

Ә Грозныйда. Мәктәпкә китте Мәрьям, гадәттәгечә – әтисе озата, мин машинаны мәктәп коймасына терәп диярлек китереп куйгач кына чыгышлы. Шуннан укытучы апасы мине чакырып алмасынмы! Ни эшләвегез, Гөлнара, сез ник мәктәпкә йөрисез? Мәктәпкә бала үзе генә дә йөри алуын мин каян белим ди?! «Ул-бу хәл булып, адашып калган очракта да балагызны өегезгә кадәр озатып куячаклар, борчылмагыз», – диде ул миңа.

Мин моңа тиз арада төшендем. Монда кечтеки балалар үзләре генә дә урамда йөри, уен мәйданчыкларында уйный, мәктәпкә бара. Рамазан аенда төнге 11–12ләрдә алар туңдырма ялый-ялый җәяүлеләр урамында йөриләр, әнкәләре-әткәләре өйдә. Куркынычсызлыктан бигрәк (ә Грозный Россиянең иң куркынычсыз шәһәре дип табылды), монда җәмгыять башка. Теләсә кайда балалар – изге, балалар – түрдә. Әминә моны аңлап алуга рәхәтләнде. Урамга чыгабыз – әле берсе, әле икенчесе кулына 50–100 тәңкә тоттыра, башыннан сөеп, битеннән чеметеп китүгә генә түз. Синең-минем бала юк, БАЛА бар. Шулай бер кафеда утырабыз моның белән, пыяла витрина артына тезеп куелган кисәк-кисәк тортларның өстенә җиләк тезелгәнен сорый бу. Мәйтәм, алдыңдагы вафлины да ашап бетермәдең ич әле, ашарлык булсаң гына ал, димен моңа. Ярар, алмыйм, диде бу. Теге вафлины хәл итә-итә чәй эчәбез. Бәтәч, күрше өстәл янында утырган ике бабайның берсе тора, официантлы витрина янына бара, Әминә сораган теге торт кисәген ала да Әминә алдына китереп куя: «Аша, кызым», – ди, башыннан сөя-сөя. Мин кып-кызыл булам, Әминә сөенә-сөенә тегенең өстенә тезелгән җиләкләрен ашарга керешә…

Урамдагы балалар шуклыгы, светофорсыз гына юл чыккан балалар белән дә шул: бөтен җирдә балаларны уздыру – закон. Яшел янамы синә, кызылмы – бала беренче урында, аннан – светофор төсләре. Шуңа безнең күршедәге беренче сыйныф кызлары үзләре генә кайта, үзләре генә китә мәктәпләренә. Әле берәрсе юл уңае арып китсә, баланы кайтарып куярга да озак сорамаячаклар.

Олы кызым Мәрьямнең кулын имгәтеп, гипста йөргән көннәре иде. Кечкенәсе чирләп китте, урамга алып чыгарлык түгел. Ә Мәрьям сәнгать мәктәбенә – шәһәрнең икенче читенә йөри, әтиләре шәһәрдә түгел. Әти-әниләр чатына язам: алай-болай берәрегезгә юл уңае түгелме, үзәк тирәсендәрәк калдырсагыз, үзе кайтып җитәр иде. Һәм беләсезме ничә кеше Мәрьямне кайтарып куярга тезелде! Анда безнең класстан берәү дә машинада йөрми икән, бөтенесе диярлек якын-тирәдә яшәү сәбәпле, тәпи-тәпи генә. Әмма шундук бер әни, үзем илтеп куям, диде, икенчесе иренә әйтәчәген, эшеннән килеп җитәчәген белдерде, өченче берәү, безнең бабай өйдә, карт булса да, башы эшли, хәзер такси ала да килеп җитә, диде.

Шоколадын кочып, коеп яңгыр яуса да, кием-салымына дым үтәргә дә өлгермәгән, подъезд төбенә кадәр машинада кайткан кызым кайтып кергәч, күңелемнән мең рәхмәт укыганмындыр. Рәхмәт сезгә, матур күңелле кешеләр!..

Гөлнара ҖӘЛИЛОВА

(Дәвамы бар)

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

2021 елда Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт премияләрен бирү турында

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт премияләре комиссиясе тәкъдимнәрен карап, **КАРАР БИРӘМ:**

2021 елда Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт премияләрен һәм **«Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт премиясе лауреаты»** исемен түбәндәгеләргә бирергә:

1. «Татарстан Республикасында балаларда йөрәк-кан тамырлары авыруларын иртә ачыклау өчен инновация технологияләрен эшләү һәм гамәлгә кертү» хезмәте өчен:

Садыйкова Динара Илгизәр кызына, медицина фәннәре докторы, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Казан дәүләт медицина университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең госпиталь педиатриясе кафедрасы доценты, кафедра мөдире, хезмәтнең җитәкчесенә;

Бабинцева Анна Анатольевнага, медицина фәннәре кандидаты, Казан шәһәренең «7 номерлы шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең неонатология буенча баш белгеченә;

Зыятдинов Айрат Илгизәр улына, медицина фәннәре кандидаты, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибына;

Игнашина Елена Германовнага, медицина фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Дәвалау һәм профилактика ярдәме идарәсе балаларга медицина ярдәме күрсәтүне оештыру һәм бала тудырганда ярдәм итү хезмәте бүлеге башлыгына;

Макарова Тамара Петровнага, медицина фәннәре докторы, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Казан дәүләт медицина университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең госпиталь педиатриясе кафедрасы профессорына;

Сабирова Динә Рәшит кызына, медицина фәннәре кандидаты, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Казан дәүләт медицина университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең госпиталь педиатриясе кафедрасы доцентына;

Сенёк Светлана Александровнага, медицина фәннәре кандидаты, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика балалар клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибының дәвалау часте буенча урынбасарына;

Фирсова Наталия Николаевнага, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика балалар клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең кардиология бүлекчәсе мөдире – табиб-педиатрына.

2. «Атмосферада радиодулкыннарның метеор-ионнар катлавында таралышы һәм һава агымнары процесслары» хезмәтләр циклы өчен:

Шерстюков Олег Николаевичка, физика-математика фәннәре докторы, «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең радиофизика кафедрасы доценты, кафедра мөдире, хезмәтнең җитәкчесенә;

Акчурин Адел Җәвит улына, физика-математика фәннәре кандидаты, «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең радиоастрономия кафедрасы доценты, кафедра мөдиренә;

Карпов Аркадий Васильевичка, физика-математика фәннәре докторы, «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең радиофизика кафедрасы профессорына;

Насыйров Игорь Альберт улына, физика-математика фәннәре кандидаты, «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең радиофизика кафедрасы доцентына;

Сулимов Әмир Илдар улына, физика-математика фәннәре кандидаты, «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең радиофизика кафедрасы доцентына;

Теплин Герман Михайловичка, физика-математика фәннәре докторы, профессор, «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең радиоастрономия кафедрасының элеккеге профессорына;

Хуторова Ольга Германовнага, физика-математика фәннәре докторы, «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең радиоастрономия кафедрасы профессорына.

3. «Татарстан Республикасында татар токымлы атлар селекция казанышын булдыру һәм файдалану» хезмәте өчен:

Хәертдинов Равил Әнвәр улына, биология фәннәре докторы, «Н.Э. Бауман исемендәге Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясе» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең биология, генетика һәм терлекләр үрчетү кафедрасы профессоры, кафедра мөдире, хезмәтнең җитәкчесенә;

Бакиров Фәнис Рәшит улына, «Бакиров Фәнис Рәшит улы» крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгына (Татарстан Республикасының Әлки районы);

Зарипов Ришат Өлфәт улына, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Терлекчелектә токым эше буенча баш дәүләт авыл хуҗалыгы идарәсе башлыгына;

Камалетдинов Илнур Наил улына, биология фәннәре кандидаты, «Н.Э. Бауман исемендәге Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясе» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең биология, генетика һәм терлекләр үрчетү кафедрасы доцентына;

Нәбиуллин Фәрит Мәсәбих улына, шәхси эшкуарга (Татарстан Республикасының Лениногорск районы);

Сафина Галина Фатыйх кызына, авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты, Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының Терлекчелек һәм токым эше департаменты директоры урынбасарына;

Сушенцова Марина Анатольевнага, авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты, «Н.Э. Бауман исемендәге Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясе» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең терлекчелек һәм зоогигиена технологияләре кафедрасы доцентына;

Хәбибуллин Айрат Гарәфша улына, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының сөт һәм ит җитештерү секторы әйдәүче киңәшчесенә.

4. «Ромашкино нефть ятмаларын үзләштерү нәтиҗәлелеген арттыру максатында соңгы баскычта нефть чыгаруны тизләтү буенча технологик чишелешләр комплексын тормышка ашыру» хезмәте өчен:

Лотфуллин Азат Әбүзәр улына, техник фәннәр кандидаты, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең «Татнефть-Добыча» структур бүлекчәсе Нефть ятмаларын эшкәртү департаменты башлыгы урынбасары, хезмәтнең җитәкчесенә (Әлмәт шәһәре);

Әбсәләмов Руслан Шамил улына, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең «Татнефть-Добыча» структур бүлекчәсе Нефть ятмаларын үзләштерү департаменты геологик-техник чаралар идарәсенең су ярдәмендә катламны еру бүлегенең нәтиҗәлелекне анализлау буенча әйдәүче белгеченә (Әлмәт шәһәре);

Әбүсәлимов Эдуард Марс улына, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең «Татнефть-Добыча» структур бүлекчәсе Нефть ятмаларын үзләштерү департаменты геологик-техник чаралар идарәсенең катламның забой яны зонасын эшкәртү бүлеге башлыгына (Әлмәт шәһәре);

Исмәгыйлев Фәнзат Җәүдәт улына, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең скважиналарны төзекләндерү һәм катламнарның нефть бирүчәнлеген арттыру идарәсе башлыгына (Әлмәт шәһәре);

Кәримов Илдар Сирин улына, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең «Татнефть-Добыча» структур бүлекчәсе Нефть ятмаларын үзләштерү департаментының геологик-техник чаралар идарәсе башлыгына (Әлмәт шәһәре);

Мөхлиев Илнур Рәшит улына, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең «Татнефть-Добыча» структур бүлекчәсе Нефть ятмаларын үзләштерү департаментының геологик-техник чаралар идарәсе башлыгы урынбасары – скважина бораулауны планлаштыру һәм геологик яктан хезмәт күрсәтү бүлеге башлыгына (Әлмәт шәһәре);

Хөсәенов Руслан Фәргать улына, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең «Татнефть-Добыча» структур бүлекчәсе Нефть ятмаларын үзләштерү департаментының нефть агымын көчәйтү һәм катламнарның нефть бирүчәнлеген арттыру идарәсе башлыгы урынбасары – су ярдәмендә катламны еру бүлеге башлыгына (Әлмәт шәһәре).

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 04 декабрь
№ ПУ-927

КАЗАНДА ЯШӘҮЧЕ НГУЕН ДАНГ НГОК:
«ТАТАРСТАНДА РӘХӘТ»

Алар өчен бәйрәмнәрнең исәбе юк. Үзләренекен дә уздыралар, Татарстанда үтүче чараларны да калдырмаска тырышалар. Бигрәк тә Сабантуйны яраталар икән. Без Яңа елны елга бер каршыласак, алар аны ике тапкыр үткәрә. Сүзем вьетнам гаиләсе турында. Гаилә хуҗасы Нгок рус телен аңласа да, авырлык белән сөйләшә. Шуңа да без күбрәк аның кызы Линь Чи белән аралаштык. Кыз үзен Лиля дип йөртә.

– Әти дә, әни дә Мәскәүдә таныша. Икесе дә бирегә эшкә килгән була. 1989 ел була бу. Бер мәҗлестә танышып, очраша башлыйлар. Күп тә үтми, алар өйләнешә. Абыем Линь туа. Әти белән әни гел эштә булгач, аны Вьетнамга җибәрәләр. Ул шунда үсә, – ди Лиля. – 7 елдан соң әтием белән әнием Казанга күчә. Аларны биредәге Вьетнам базары хуҗасы чакырып ала. Икесе дә сату эшенә керешә. 2000 елда мин туганмын. Мине няня үстерде. Өч яшьтә рәхәтләнеп татарча сөйләшә белгәнмен. Мәктәпкә кергәнче, мине дә абыем янына, әби-бабаема илтеп куйганнар. Аннан кайтканда, татарчам онытылган иде. Мәктәптә укый башлагач, яңадан исемә төште.

Нгок белән хатыны Ха Казандагы бер вьетнам кафесында пешекче булып эшлиләр икән. Татарстан халкын үз ризыклары белән сыйлыйлар. Үзләре безнең гөбәдияне ярата.

– Биредәге халык бәрәңге, токмач, ит ашаса, без үзебезчә тукланабыз. Дөге пешерәбез, күп итеп яшелчә ашыйбыз. Татар дусларыбыз күп. Алар нинди генә ризык белән сыйламый, – ди Нгок.

Алардан Яңа ел бәйрәме хакында да сораштым. Без аны 31 декабрьдә каршы алсак, Нгуен Данглар гаиләсе ул көнне дә бәйрәм итә, кытай календаре буенча февральдә дә күңел ачалар. Бәйрәмгә дөге пирогы пешерәләр икән. Лиля сөйләвенчә, ул казанда 8–10 сәгать пешә икән. Бәйрәмдә алар бер-берләренә бүләк түгел, акча бирәләр. Аеруча балалар һәм өлкәннәргә зур игътибар күрсәтәләр. «Акчаны кызыл конвертка салып бирергә кирәк», – ди Лиля.

Кыз 4 телдә иркен сөйләшә. Вьетнам, инглиз, рус, татар телләрен белә.

Гаиләләре белән татар җырларын да тыңлыйлар әле алар. Нгок Зөлфирә һәм Алмаз Мирзаяновлар иҗатын ярата икән.

– Аларның чыгышын көннәр буе тыңларга әзермен, – ди ул. Лиля исә барлык җырларны үз итә.

– Нинди генә вьетнам бәйрәме булмасын, без Вәсилә Фәттахова башкаруындагы «Туган як» җырына биибез. Аны әллә ничә кат җырлатабыз, – ди ул.

Туган як дигәннән, алар үз илләрен бик сагына. Уллары Линь яшәргә шунда киткән. Өйләнеп, балалар үстерә икән. Алар җай чыккан саен, якыннары янына барып тора. Линь да кунакка килә икән. Лиля туризм юнәлешендә белем ала. Аның бер дә Татарстаннан китәсе килми.

– Казан – матур, яшәр өчен уңайлы шәһәр. Мин аны бик яратам. Безгә монда барлык шартлар да тудырылган. Халыклар дуслыгы йортында үз милләттәшләребез белән еш очрашып торабыз, – ди ул. – Казанда тугач, ул миңа бик якын. Дусларым күп. Һәр милләт кешесе белән тату яшибез. Әтием, татар егетен яратасың икән, без каршы түгел, дип тора. Белеп булмый, язмышка ни язылгандыр. Кем булса да, яхшы кеше очрасын!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Эчке эшләр органнарында күпьеллык намуслы хезмәте, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытуга зур өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы ветераны, отставкадагы милиция подполковнигы **Ритман** Илья Викторович **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Татарстан Республикасының социаль-икътисади потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе **Нәфыйгин** Альберт Илдар улы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

* * *

«Татэнергосбыт» акционерлык җәмгыятенең мәгълүмат технологияләрен үстерү бүлеге башлыгы **Наумова** Ландыш Рәис кызына **«Татарстан Республикасының атказанган мәгълүматлаштыру һәм элемтә хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы наркотиклар әйләнешен контрольдә тоту идарәсенең наркотикларның әфьюн, каннабис төрләре һәм кокаинның законсыз әйләнешенә каршы көрәшү бүлеге башлыгы урынбасары – бүлекчә (наркотикларның каннабис төренең законсыз әйләнешенә каршы көрәшү бүлекчәсе) башлыгы, полиция подполковнигы **Гарифуллин** Равил Фәрит улына **«Татарстан Республикасы буенча атказанган эчке эшләр органнары хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, әнисе

АЛЕКСЕЕВА Валентина Николаевна

вафат булу сәбәпле, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Мобилизацион әзерлек һәм махсус программалар идарәсенең Ситуацияләр үзәге эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге башлыгы – Идарә башлыгы урынбасары Алексеев Владимир Гаврииловичның авыр кайгысын уртаклаша.

Спорт

Күп булуның файдасы юк

Узган атнада Дубайда уйнап кайткан «Ак барс» дүшәмбе көнне Казанда «Барыс» белән очрашты. Матч Нур-Солтан командасының җиңүе белән тәмамланды. Дмитрий Квартальнов уенчылары бу юлы да бер кешегә күбрәк уйнау мөмкинлегеннән файдалана алмады.

Казан командасының бу кимчелеген телгә алу юкка түгел. Ник дигәндә, «Ак барс» күплектә уйнау буенча КХЛда соңгы урынга төште. Якташларыбыз көндәшнең кагыйдә бозуы аркасында барлыкка килгән мөмкинлекнең 11,4 процентын гына нәтиҗәле файдалана. Бу сезонда алар 125 мәртәбә бозга бер кешегә күбрәк чыкканнар, нибары 14 алка кертә алганнар. Чагыштыру өчен, «Авангард» 119 мөмкинлектән 36 алка керткән. «Ак барс» ни өчен булдыра алмый? Бу сорауны баш тренер Дмитрий Квартальновка һәр матчтан соң диярлек бирәләр. Ул һәрвакыт сәбәпләр табарга тырыша, тырышканнарын әйтә, әмма уен гына үзгәрми. Ә бит күплектә уйнаганда алка кертү көчле командаларның төп сыйфатларыннан берсе санала.

Киләсе ике очрашуны «Ак барс» үз бозында «Нефтехимик» һәм «Салават Юлаев»ка каршы уздырачак. Аннан соң КХЛда бер атналык тәнәфес булачак: Россия җыелма командасы Еврохоккейтурның Мәскәүдә узасы этабында – Беренче канал кубогында чыгыш ясый. Җыелма командага «Ак барс»тан капкачы Тимур Билалов, һөҗүмчеләр Артем Галимов белән Дмитрий Воронков чакырылган. Россия хоккейчылары 15 декабрьдә – Канада, 16сында – Швеция, 18ендә – Чехия, 19ында исә Финляндиягә каршы уйный.

Илнар ХӨСНУЛЛИН

	команда	уен	очко
1	Металлург	36	57
2	Трактор	39	57
3	**Ак барс**	**37**	**49**
4	Салават Юлаев	37	47
5	Авангард	36	44
6	Сибирь	37	42
7	Автомобилист	37	37
8	Нефтехимик	36	35
9	Амур	38	35
10	Барыс	36	34
11	Куньлунь	36	22
12	Адмирал	37	19

ak-bars.ru

Белми калмагыз!

«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»ГА ЯЗЫЛУЧЫГА – МИНИ-ТРАКТОР

БҮЛӘКНЕ АЛУ ШАРТЛАРЫ

1 2022 елның беренче яртыеллыгына 6 айга «Ватаным Татарстан» газетасына язылырга.

2 Язылу квитанциясен безгә җибәрергә: «Ватсап» (89179270040) яки почта аша (420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт, «ВТ» газетасы редакциясе), яки электрон адреска (info@vatantat.ru).

БЕЛЕШМӘЛӘР ӨЧЕН ТЕЛЕФОН: 8-917-927-00-40

Җиңүче җирәбә юлы белән ачыкланачак. Квитанцияләр 2022 елның 16 гыйнварына кадәр кабул ителә, җирәбә 20 гыйнвар көнне үткәреләчәк.

Акцияне оештыручы: «Ватаным Татарстан» газетасы ДБУ, акцияне уздыру вакыты 2021 елның 1 ноябреннән 2022 елның 15 февраленә кадәр. Тулырак мәгълүмат vatantat.ru сайтында.

УРАЛЕЦ ТОРГОВЫЙ ДОМ МЫ ПРОДАЁМ НАДЁЖНОСТЬ

АКЦИЯНЕҢ ИГАНӘЧЕСЕ – «УРАЛЕЦ» СӘҮДӘ ЙОРТЫ

- ✓ мини-тракторлар;
- ✓ барлык төр тракторлар өчен запас частьлар;
- ✓ җир эшкәртү, чәчү, җыйнау өчен асылмалы җиһазлар.

Казан ш., Мамадыш тракты, 35А; Чаллы ш., Казан проспекты, 252/1; Әлмәт ш., Советская урамы, 42А.

ТЕЛЕФОННАР: 8-927-465-12-94, 8-987-931-55-50

ГАЗЕТАГА ЯЗЫЛУ ЫСУЛЛАРЫ



1 ПОЧТА БҮЛЕКЧӘЛӘРЕНДӘ

2 ОНЛАЙН: vatantat.ru сайтындагы сылтама аша газетага язылу бик уңайлы һәм тиз. Программа үзе адымлап алып бара.

Әлеге QR-код ярдәмендә телефон аша газетага язылырга һәм акча түләргә мөмкин.

Сөенечле хәбәр!

2022 елның беренче яртыеллыгы өчен 6 айга язылу бәяләре

П2435 атнага бер, җомга килә ~~465 сум~~ 404,04 сум

П2409 Сишәмбе, чәршәмбе, җомга, шимбә килә ~~1000,92 сум~~ 859,08 сум

6–16 декабрь көннәрендә ташламалы бәяләр!

Реклама 16+

АММАР ХӨСӘЙН:

«БЕЗ БУЛМАСАК, ТАГЫН КЕМ?!»

Рәхмәт, табиб!

«ВТ» укучылары өчен Аммар Хөсәйн исеме күптән билгеледер, мөгаен. Бу егет белән пандемия башланган чорда ук танышкан идек. Ул беренчеләрдән булып «Ярдәм яңашә» акциясенә кушылып, волонтер булып йөрде. Моңа өстәп Аммарның булачак табиб икәне дә исегездәдер. Хәзерге вакытта ул Казан федераль университетының 5 курсында белем ала. Уку белән эше бергә атлый, Аммарның күп вакыты «кызыл зона»да уза. Хезмәтен саннар теленә күчереп әйтсәк, бирегә ул 3 мең сәгать вакытын уздырган, Гыйрак егете дистәләгән татарстанлының гомерен саклап калуга өлешен керткән.

– Һөнәрем буенча мин – булачак табиб. Шуңа күрә хастаханәдә, «кызыл зона»да булуым да табигый күренеш бит инде. Кайда кирәк, шунда булырга тиеш без. Хәзерге вазгыятьтә исә без медицина хезмәткәрләренә кирәк, – ди Аммар, тыйнак кына.

Булачак табиб бала чагыннан ук кешеләргә ярдәм итәргә хыялланган. Шуңа да медицина юлын сайлаган инде ул. Пандемия башлангач та, иң беренчеләрдән булып, ярдәм итәргә дип, «кызыл зона»га эшкә керә. Хәзер укудан соң Республика йогышлы авырулар клиникасына йөгерә. Биредәге «кызыл зона»да Аммарны, коронавирус кичереп, янә тормышка кайтучы сырхаулар көтә.

Билгеле булганча, чирдән соң тернәкләнү процессы озак вакыт дәвам итә әле. Булачак табиб андыйлар белән дәвалау физкультурасы үткәрә. Күп очракта – гамәле, кирәк урында җылы сүзе белән ярдәм көткән күпме кешене аякка бастыра ул.

– Сырхауларның кислородын көйләү, нормага күтәрү, кан әйләнешен яхшырту юнәлешендә эшлибез, физик һәм сулау күнегүләре ясыйбыз. Коронавирус эләктергән сырхауларның хастаханәдә бер айлап ятуы да ихтимал, шуңа күрә сәламәтләнә башлагач мускулларны хәрәкәтләндерү дә бик мөһим, – дип сөйли Аммар. – Пандемия безнең һәркайсыбыздан дөрес, уйланылган адымнар ясауны таләп итә. Бу аяныч нәтиҗәләр азрак булсын өчен кирәк. Медик-волонтерлар табиблар җилкәсенә төшкән авырлыкның никадәр зур булуын яхшы аңлый. Шуңа да хәлебездән килгәнчә ярдәм итәргә тырышабыз. Иңне-иңгә куеп, пандемиянең беренче «дулкын»ыннан башлап эшлибез инде. Бу эшем белән горурланам. Моннан тыш, мин республикадагы «кызыл зона»ларда эшләүче медик-волонтерларның барысы өчен дә җавап бирәм. Минем карамакта 30лап кеше. Алар, нигездә, 7 нче шәһәр хастаханәсе, Республика клиник хастаханәсе кебек зур медицина оешмаларында эшли. Авыр чакта кешеләргә ярдәм итә алуыбызга сөенәбез генә. Волонтер буларак, биредә тәҗрибә дә туплыйбыз, тәрбия дә алабыз. Бу – чын тормыш мәктәбе. Ул безгә сайлаган һөнәребезнең асылын аңлата. Безнең һөнәр – ярдәм көткәннәргә булышу ул.

Укып бетергәч тә, киләчәген Казанда күрә Аммар. Республикада калырга исәпли, Россиянең күпчелек төбәкләрен йөреп чыккан кеше буларак, күңеленә иң якыны дип Татарстан башкаласын атый.

Эше турында тыйнак кына сөйләсә дә, аның катлаулы булуын яшерми. «Без медицина хезмәткәрләренең барысы белән дә бердәм механизм кебек эшләдек. Нәтиҗәле хезмәтнең нигезе шунда дип саныйм», – ди Аммар. Ару-талуларны исә сырхауларның рәхмәт сүзләре оныттыра. Үз тәҗрибәсендә бу сүзләрне ул күп ишеткән инде. Аммар кебекләргә «Ходайдан бирелгән табиблар» диләр.

Медик-студентның тәҗрибәсендә авыр очраклар да юк түгел. Берсендә Казаннан 22 чакрым ераклыкта яшәүче бер гаиләгә көн саен йөрергә туры килгән. Бу гаиләдә чир белән кыз бала көрәшкән. Аммар сүзләренчә, сырхау белән эшләгәндә иң авыры аны терәләсенә ышандыру булган.

– Ул инде үзенә психологик киртә корып куйган иде. Дарулар эчәргә дә, дәваланырга да теләмәде. Ябык ишек аша 3–4 сәгать аның белән сөйләшергә туры килде. Тыныч кына аңлаткач, аңлады, даруларны да кабул итә башлады. Нәтиҗәдә терелде дә.

Шәфкать иясенең волонтерлык һәм һөнәри эшчәнлеге төрле конкурсларда да лаеклы бәһасен ала. Әле күптән түгел ул Ханты-Манси округында узган «Ел студенты. Медиклар» конкурсыннан махсус приз белән кайтты. Бүләкләргә, мактау сүзләренә сөенеп утырырга вакыты да булмагандыр инде аның, чөнки аэропорттан туп-туры эш урынына – «кызыл зона»га юл тоткан Аммар.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

КУРЧАКЛАР ИЛЕНДӘ

Ул курчакларына матурлык кына түгел, җан да өрә кебек. Һәркайсына газиз баласына караган кебек карый. Остаханәсендә үзе белән бергә эшләүче туташ-ханымнарны да шуңа өйрәтеп бетергән. Милләте буенча – алман, йөз-кыяфәте, сөйләшүе буенча коеп куйган татар кызы Галина Геркның үзе турында гына да калын бер китап язарлык.

Алман илендә фрау булып йөрисе Галина ханымны Азнакай кадәр Азнакайга нинди җилләр ташлаган, дисездер инде. Гел чит яклар түгел ул аның өчен, әнисенең туган һәм бераз торган җире. Ирекле авылы кызы Мөнҗияне язмыш алман егете Альвис белән кавыштыра. «Авыр елларда кавыша алар. Ул чакта кайчандыр патша чакыруы белән Саратов өлкәсенә килеп төпләнгән Идел буе немецларын бер көн эчендә, товар вагоннарына төяп, Себергә китәргә мәҗбүр итәләр. Әти белән әни шунда танышa», – дип искә алды Галина Герк.

Әтисенең тарихи Ватаны Геркларга җир дә бирә. Хәзер ул җирләрдә – Баден-Вюртембергта Галина ханымның туганнары яшәп ята. «Минем дә алар янына китү теләгем көчле иде. Ләкин улым бу фикеремнән кире кайтарды. Туганнарым белән еш күрешәбез. Алар торган урыннарның матурлыгын белсәгез!» – ди ул.

Алтмыш яшендә Галина Герк курчак ясап карарга була. «Кечкенә чагым авылда узгач, андагы апа-әбекәйләрнең киенү рәвешләре хәтергә сеңеп калган. Шуларны күз алдына китереп, матур милли киемле кызчыклар ясыйсы килде. Менә шулай хыяллана-хыяллана, ялгыша-ялгыша бу эшне бүгенге һөнәремә әйләндердем», – дип сөйләде ул, матурлык буенча бер-берсеннән калышмаучы курчакларына ишарәләп.

Сылу курчакларның үз туган йортлары да бар. Азнакайның нәкъ уртасында диярлек Галина Герк җитәкчелегендә «Азнакай сувенирлары» остаханәсе эшли. Бу якларга килеп чыгып, бөтенләй үзгә дөнья күрәсегез килсә, әлеге остаханәне сез дә читләтеп үтмәгез. Безне кунак иткәндә, курчакларның «әнкә»се ярдәмчеләре турында да сөйләде. Галина ханым мөмкинлекләре чиклеләр белән эшли икән. Күбесенең тормыш хәлләре авыр. «Өйдә генә эшләүче кызым да бар. Ул инвалид баласын карый, курчакларга да вакыт таба. Бездән бераз аерылсалар да, матурлыкны күрә, тоя

белә алар. Иң мөһиме шул бит», – дип сөйләде ул.

Галина ханым курчакларның нинди буласын төнлә дә уйлап ята икән. Рәсемгә төшерә, нинди күлмәк, калфак кидерәчәге турында хыяллана. Курчакның башын, аяк-кулларын, гәүдәсен дә үзләре коя алар. Моның өчен скульптуралар ясый торган махсус балчык һәм махсус формалар кулланалар. Курчакның йөз чалымнары өчен Галина ханым җаваплы. «Үтә вак эш бу. Бигрәк тә кечкенә курчак ясарга алынсаң. Игътибар итсәгез, курчакларның һәркайсы үзенчәлекле. Киемнәренә түгел, йөзләренә карагыз. Шулай килеп чыга инде менә. Сайлана башлагач, кешеләр кайсының елмаюын, кайсының күзләрен ошатып ала. Ә миңа һәркайсы кадерле», – дип, бәйнә-бәйнә барын да аңлатты ул.

«Азнакай сувенирлары»н белмәгәннәр Татарстанда гына түгел, Россиядә дә аз кала бугай инде. Тик аңа карап кына эшләр гел гөрләп тормый, ди Галина ханым. «Пандемия сәбәпле, эшләр кыенлашты. Мин бит берүзем түгел. Беренчедән, кешеләрем, икенчедән, техникам бар. Матурлыкка сокланып кына яшәп булсын иде ул, ләкин акчасы да кирәк. Ничек кенә булмасын, өметемне өзмим. Хыялларым көчлерәк – бирешәсе килми», – ди ул.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 7387 данә
Гомуми тираж – 17167 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 379

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+